| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАЛОМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2022 Кече Мәми ав. № 11

Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең бюджет проектын әзерләү тәртибе һәм сроклары турында» 2022 елның 10 октябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең бюджет проектын әзерләү тәртибе һәм сроклары турында» 2022 елның 10 октябрендәге 10 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Финанс-бюджет палатасы» сүзләре алдыннан «тәкъдим итәргә» сүзләрен өстәргә;

1 пунктның 10 пунктчасында «консолидацияләнгән» сүзен төшереп калдырырга;

3 пунктның 2 һәм 3 пунктчаларында пункта «бюджет акчалары» сүзләреннән соң «Кече Мәми авыл җирлеге» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә https://mmemin-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Е.Н.Алексеева